ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 19 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 38 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 өлештә «әзерләүдән тыш)» сүзләреннән соң «, урман хуҗалыгы регламенты, махсус сакланылучы табигать территориясе турындагы нигезләмә» сүзләрен өстәргә;

2) 7 өлештә «органнары» сүзеннән соң «, ә линия объектларын урнаштыру планлаштырыла торган җир кишәрлекләрен урман фонды җирләре составыннан башка категория җирләренә күчерү кирәк булган очракта, шул исәптән мондый объектларны файдалануга керткәннән соң да, федераль башкарма хакимиятнең урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә тикшереп тору һәм күзәтчелек итү, шулай ук урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү һәм дәүләт милке белән идарә итү функцияләрен гамәлгә ашыручы органы» сүзләрен һәм түбәндәге эчтәлекле җөмләләр өстәргә: «Махсус сакланылучы табигать территориясенә карата әзерләнгән территорияне планлаштыру документлары расланганчы, алар үз карамагында тиешле махсус сакланылучы табигать территориясе булган дәүләт хакимияте башкарма органы яисә җирле үзидарә органы белән килештерелергә

тиеш. Килештерү предметы урман законнары, махсус сакланылучы табигать территорияләре турындагы законнар таләпләре нигезендә урман фонды, махсус сакланылучы табигать территорияләре җирләре чикләрендә капиталь төзелеш объектларын урнаштыруны рөхсәт итүдән, шулай ук линия объектлары булып тормаган капиталь төзелеш объектларын планлаштырып урнаштыруның үз чикләрендә мондый объектларны урнаштыру планлаштырыла торган территориягә карата расланган урман хуҗалыгы регламентына, махсус сакланылучы табигать территориясе хакындагы нигезләмәгә туры килүеннән йә, Россия Федерациясе законнары нигезендә җир кишәрлекләрен урман фонды җирләре, махсус сакланылучы территорияләр һәм объектлар җирләре составыннан башка категория җирләренә күчерү рөхсәт ителсә, мондый күчерү башкарылган очракта капиталь төзелеш объектларын урнаштыру мөмкинлегеннән гыйбарәт. Территорияне планлаштыру документларын килештерү срогы аларның әлеге өлештә каралган дәүләт хакимияте органына яисә җирле үзидарә органына кергән көненнән алып утыз көннән дә артык була алмый.»;

3) түбәндәге эчтәлекле $17^1$ өлеш өстәргә:

«$17^1$. Капиталь төзелеш объектын автомобиль юлының юл буе полосасы чикләрендә урнаштыруны күздә тоткан территорияне планлаштыру документлары расланганчы, алар автомобиль юлы хуҗасы белән килештерелергә тиеш. Территорияне планлаштыру документларының килештерү предметы автомобиль юлында күз күреме начар булмавын һәм юл хәрәкәте иминлегенең башка шартларын тәэмин итүдән, автомобиль юлын һәм аның составына керә торган юл корылмаларын тоту, ремонтлау, шулай ук автомобиль юлын реконструкцияләү территориаль планлаштыруның, территорияне планлаштыруның расланган документларында каралган очракта, мондый реконструкцияләү эшләре үткәрү мөмкинлеген саклаудан гыйбарәт.»;

4) түбәндәге эчтәлекле $17^2$ өлеш өстәргә:

«$17^2$. Капиталь төзелеш объектын урнаштыру өчен территорияне планлаштыру документларын әзерләү таләп ителгән мондый объектны автомобиль юлының юл буе полосасы чикләрендә төзүгә, реконструкцияләүгә автомобиль юлы хуҗасының ризалыгы 2018 елның 4 августына кадәр алынган булса, территорияне планлаштыру документларын автомобиль юлы хуҗасы белән килештерү таләп ителми.»;

5) түбәндәге эчтәлекле $17^3$ өлеш өстәргә:

«$17^3$. Территорияне планлаштыру документларын килештерү мәсьәләләрендә дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) автомобиль юллары хуҗалары арасындагы фикер каршылыклары Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 30 ноябрь
№ 90-ТРЗ